Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Исполнительный комитет
Старогришкинского сельского поселения
423642 с.Старое Гришкино, ул.
Молодежная, д.1
Тел.(885549)3-51-18

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Иске Гришкино
авыл башкарма комитеты
423642 Иске Гришкино авылы, Яшьлэр
ур.1 нче йорт
Тел.(885549)3-51-18

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

28.03.2025 ел №12

Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино
авыл башкарма комитетнын 2025 елның 3 мартындагы
11 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге Уставы нигезендә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Иске ГРишкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. халык күплэп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә буш урыннар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар:

-Иске Гришкино авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Яшьләр урамыннан 100 метр ераклыкта (авыл мәдәният йорты артындагы мәйданчыкта);- Сәйтәк авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Яшьләр урамыннан 50 метр ераклыкта (әйләнеп узу юлы буйлап);

- Карманково авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Кыр урамыннан 100 метр ераклыкта;

- -Илькино авылының төньяк-көнбатыш өлешендә, Зеленая урамыннан 50 метр ераклыкта (Юрашка елгасы ягына).

Әлеге территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар куярга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Иске Гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев